# Хроника научной жизни

## ТӘГЪЗИЯНАМӘ СВЕТЛАНА ХАНЫМ ЧЕРВОННАЯ (1936–2020)

**Дустыбыз хәм хезмәттәшебез Светлана ханым Червонная 2020 елның 9 ноябрендә фани дөньядан бакыйлыкка күчте һәм кичә Торунь шәһәрендә җирләнде.**

Ул ИКАТАТка нигез салган вакыттан бирле, безнен рухи анабыз буларак, соңгы сулышына кадәр институтның Гыйльми Шурасының актив әгъзасы булып торды. Тормышка ашырылмаган уртак планнарыбыз, тәмамланмаган эшләребез бик күп калды, ләкин һәрберебез дә бу дөньяда вакытлы кунаклар икәнлеген танырга мәҗбүрбез.

***Светлана ханым Червонная «әбекәй»нең изге хатирәсенә***

Светлана ханымның беренче һәм иң олы мәхәббәте – Татар, бигрәк тә Кырым татар халкы булды. Кырым татарларның үз тарихи ватаннарына кайту хокукын яклап, ул армый-талмый көрәш алып барды. Кырым татарлары да аны һичшиксез үз иттеләр, якын күрделәр. Татар тарихын һәм мәдәниятен Европада һәм дөнья күләмендә популярлаштыруга, аны фәнни өйрәнүгә ул үзенең күп вакытын, энергиясен сарыф итте. Китаплары белән генә түгел, конференцияләр, төрле җәмәгать чаралары, протестлар, дискуссияләр оештырып, ул яшь галимнәрне азчылык халыкларның хокукларын саклауга чакырды, демократия тарафдарлары булырга өндәде. Аның өчен галим булу – ул югары дәрәҗәдә социаль җаваплылыкка ия булуны аңлата иде.

Светлана ханымның тырышлыгы белән Николай Коперник исем. Университетта (Торунь, Польша) уникаль фәнни үзәк – «Татар Китапчылыгын өйрәнү үзәге» (CENTER FOR KITAB STUDIES) төзелде.

Светлана Червонная Мәскәү дәүләт университетында укып, СССР Сәнгать Академиясендә диссертация яклады, Тбилиси Дәүләт университеты һәм Карачай-Чиркәс Дәүләт университетының шәрәфле әгъзасы, «Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемгә ия булды. Ул киң гыйлемле мәдәният белгече, профессор, нәфис сәнгать тәнкыйтьчеләренең иң абруйлысы иде. Татар мәнфәгатьләрен бөтен дөнья киңлегендә кайнар яклаучыларның алгы сафында баручыларның берсе иде.

Галимәнең тормышы һәм фәнни эшчәнлегенең иң күп өлеше Казан, Татарстан, Кырым, гомумән алганда, Татар дөньясы, шулай ук, Германия, Берлин, Магдебург һәм Кавказ белән бәйле иде.



Светлана Червонная һәм
Мисте Хотопп-Рике

«Совет Татарстаны сәнгате» (1978), «Россия халыкларының заманча ислам сәнгате» (2008) һ.б. китаплары татар сәнгате һәм Россиянең башка мөселман халыклары сәнгатьләрен фәнни өйрәнүдә беренче карлыгачлар булып, күп еллар дәвамында әлеге өлкәдә өлге, үрнәк булырлык уникаль хезмәтләр рәтендә саналып киләләр.

Светлана ханым Берлин һәм Магдебургта да күпсанлы мәкаләләр, китаплар бастырды, конференцияләр оештырды. Мисал итеп Германия Бундестагы, Тышкы эшләр министрлыгы һәм Азчылыклар эшләре секретариатындагы фәнни чараларны атап узарга мөмкин.

Ул һәрчак милли мәдәниятләр һәм аларның үзара йогынтысы, Россия һәм СССР халыкларының милли хәрәкәте, аларның сәнгатьтә чагылышы белән кызыксынды.

Светлана ханымны белгән барчабыз да, аны сәләтле һәм фидакарь галим, көчле ихтыярлы зат, армас-талмас көрәшче, үзенең фәнни һәм тормыш кыйбласына тугрылыклы калган, зур рухи көчкә ия булган шәхес, зирәк һәм ярдәмчел зат буларак истә калдырачак.

Пандемия чоры күрешүләрне чикләде, Варшавадагы быелгы Төркият фәннәре һәм DAVO Конгресслары, Майнцта Төркиятче галимнәр көннәре 2021 һәм 2023 елларга күчерелде, кызганыч, уртак китаплар, проектлар тәмамланмый калды, шулай ук безнең Марсель һәм Ретимнодагы Җәйге мәктәпләребез галимәнең мөһим өлешеннән мәхрүм калды.

Кырым, Татарстан, Польша, Австрия, Германиядәге хезмәттәшләребез белән бергә, без бәхәсчән, шат күңелле, кешелекле галимәбезне, күпләребезне тугры юлга өндәүче, сирәк академик юнәлешне популярлаштыручы, «кече халыкларга» алга таба үсеш юлында ныклы таяныч булып, зур ышаныч биргән, аларга хөрмәт күрсәткән; золымга, дик-

татурага һәм Исламга карата дошманлыкка каршы нык торучы олы затыбызны югалтуыбызны авыр кичерәбез.

**Гаиләсе һәм якыннарының кайгысын ихлас уртаклашабыз.**

**ИКАТАТ** әгъзалары:
**Dr. Мисте Хотопп-Рике**
**Dr. Штефан Тайлиг**
**Моника Горка**
**Марат Гибатдинов**
**Илдар Харисов**
**Доминик Якуб Напиводски**
**Җәмилә Умерова**
**Dr. Хөсәен Чичек**
**Dr. Рамазан Алпаут**

2020 ел 14 ноябрь.

---

## OBITUARY SVETLANA MIKHAILOVNA CZERVONNAJA (1936–2020)

**We mourn for our friend and colleague Svetlana Czervonnaja. She died on November 9, 2020 and was buried yesterday in Toruń.**

She was godmother at the cradle of our institute and until the end she was an active member in the Advisory Board of ICATAT. We still had many plans together, but we must painfully acknowledge that time is finite for each of us.

***In blessed memory of our Svetlana khanum "Babushka" Czervonnaja.***

The first and most important love of Svetlana khanum were the Tatars, especially Crimean Tatars. The fight for the right of the Crimean Tatars to return to their historical homeland was their "Carthage", and the Crimean Tatars therefore rightly consider her as one of them. She has always devoted much energy and attention to researching and popularizing the history and culture of the Tatars in Europe and around the world, not only with her books, but also with public activities, protests, conferences and discussions that encouraged young scholars, to consistently stand up for minority rights and democracy. For her, science was not an ivory tower, but a social responsibility. Thanks to her efforts, a unique institution was founded, the Tatar Religious Literature Research Center (CENTER FOR KITAB STUDIES) at the Nicolaus Copernicus University in Torun (Poland). She graduated from the Moscow State University of M.V. Lomonosov, finished postgraduate studies at the Academy of Fine Arts in the USSR. She held the titles of

Doctor Honoris Causa of the Ivan Javakhishvili Tbilisi State University (Georgia) and the Karachay-Cherkess State University (Russian Federation).

Svetlana Mikhailovna Czerwonnaja was an art critic, cultural scientist, professor, Honoured Artist of the Republic of Tatarstan, a passionate advocate of Tatars all over the world. A significant part of her life and scientific interests is connected with Kazan, Tatarstan, the Tatars in general, but also with Germany, Berlin and Magdeburg, Crimea and the Caucasus. Her books "The Art of the Soviet Tatars" (1978) and "Contemporary Muslim Art of the Peoples of Russia" (2008) were the first and remained for a long time unique, comprehensive studies on the art of the Tatars and other Muslim nations in Russia. In Berlin and Magdeburg she also published many texts and books, she initiated conferences and meetings, for example in the German Bundestag, German Foreign Office and the Secretariat for Minority Issues.

She was always interested in national cultures, the processes of their interaction and mutual influence, the national movements of the peoples of the Russian Federation and the Soviet Union, and the expression of their ideals in art.

Svetlana khanum will be remembered by all who knew her as a talented and enthusiastic scientist, as a woman of unyielding will, as an uncompromising fighter, faithful to her scientific and civic Credo as an incredibly energetic and wise, responsive person.

The pandemic period has made a reunion impossible this year, the Turkish Studies Congress in Warsaw, the DAVO Congress in Warsaw and the Turkologists' Day in Mainz have been postponed to 2021 and 2023 respectively, joint book projects remain unfinished and our summer school in Marseille and Rethimnon will now have to do without her.

Together with our colleagues from the Crimea, Tatarstan, Poland, Austria and Germany, we mourn the loss of a quarrelsome, cheerful, humane academic who was a guide for many of us, popularized rare academic disciplines, gave confidence and respect to "small nations" and resolutely opposed despotism, dictatorship and hostility to Islam.

**We express our sincere condolences to family and friends.**

**Members and Fellows of ICATAT**
**Dr. Mieste Hotopp-Riecke**
**Dr. Stephan Theilig**
**Monika Górka**
**Marat Gibatdinov**
**Ildar Kharissov**
**Dominik Jakub Napiwodzki**
**Dzhemile Umerova**
**Dr. Hüseyin Çiçek**
**Dr. Ramazan Alpaut**

14th November 2020